РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ НИЖНЕКАМСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423586, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12
тел./факс (8555) 41-70-00

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТҮБӘН КАМА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

423586, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
тел./факс (8555) 41-70-00

РЕШЕНИЕ — КАРАР

№ 41 — 2024 елның 8 октябре

**Түбән Кама муниципаль районы Советының 2018 елның 28 ноябрендәге 73 номерлы карары белән расланган бушлай файдалануга муниципаль мөлкәтне тапшыру турындагы шартнамәнең типик формасына үзгәреш кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставының 73 статьясы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2018 елның 28 ноябрендәге 73 номерлы карары белән расланган муниципаль мөлкәтне түләүсез файдалануга тапшыру турындагы шартнамәнең типик формасына, 2 бүлегенең 2.4 пунктының җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

"- мөлкәткә хезмәт күрсәтүгә мөстәкыйль шартнамәләр төзергә, мөлкәтне карап тоту чыгымнарын, шул исәптән мөлкәтне карап тоту буенча эксплуатацияләү, коммуналь һәм башка чыгымнарны (оператив идарәдәге һәм муниципаль биремне үтәү кысаларында районның муниципаль бюджет яисә автоном учреждениеләренә тапшырыла торган мөлкәттән тыш) тотарга;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-икътисадый үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы — Р.Х. Муллин